# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Зур Полянка авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Баран авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Зур Полянка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокллы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту;
2) авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
3) торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
4) су челтәрләрен реконструкцияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зур Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.»

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Зур Полянка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **Н.И. Александрова**